КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 26 март г.Казань № б-498

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәте җитәкчесе һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры тарафыннан расланган «Россия Федерациясендә кызамыкны һәм кызылчаны элиминацияләү, эпидемик паротит белән спорадик дәрәҗәдә авыруга ирешү» (2026 – 2030 еллар) програмасын тормышка ашыру чараларының илкүләм планы, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Йогышлы авыруларны профилактикалау буенча санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 3.3686-21 нче СанПиН санитария кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау» 2021 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган «Йогышлы авыруларны профилактикалау буенча санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 3.3686-21 нче СанПиН санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә Татарстан Республикасы халкының санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2026 – 2030 елларга Татарстан Республикасында кызамыкны һәм кызылчаны элиминацияләүне, эпидемик паротит белән спорадик дәрәҗәдә авыруга ирешү чараларының республика планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, б-2324 нче боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин